ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Урта Камышлы авылы

КАРАР

17 декабрь 2019 ел

№ 5

2020 елга мәҗбүри яки төзәтү эшләре төрләрен һәм мәҗбүри яисә төзәтү эшләре рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында

«Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри эш төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында» 16.11.2012 ел, ПР-43-6 номерлы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы Президиумының карарын үтәү йөзеннән (Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексына 2012 елның 8 июнендә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә), мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру максатларында), административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы нигезендә һәм законлы көченә кергән суд карары буенча административ җәза үтәү рәвешендәге мәҗбүри эшләрнең мәҗбүри хезмәт булып саналуын исәпкә алып, Урта Камышлы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Хөкем ителүчеләрнең мәҗбүри яки төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү өчен мәҗбүри һәм төзәтү эшләре төрләрен билгеләргә:

- Төзекләндерү: территорияләрне чистарту, яшелләндерү, җир эшләре, юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау эшләре.
- территорияләрне санитар чистарту.
- Төяү-бушату эшләре.

Җинаять башкарма инспекциясе белән килешү буенча, алдан һәм һөнәри әзерлекне таләп итми торган башка төрле хезмәт эшчәнлеге төрләре.

2. «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәү өчен объект итеп:

- Урта Камышлы авыл җирлеге администрациясен билгеләргә.

3. «Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү өчен объект итеп:

- Урта Камышлы авыл җирлеге администрациясен билгеләргә.

4. Әлеге карарны Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Нурлат районы буенча филиалы белән берлектә төзәтү эшләренә хөкем ителгән һәм Урта Камышлы авыл җирлеге территориясендә яшәүче затларга карата суд карарлары үтәлешен тәэмин итү өчен җибәрергә.

5. Карарны мәгълүмат стендларына һәм «Интернет»челтәрендәге рәсми сайтка урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Н.А. Баймяшкина

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 17 декабрендәге 5 номерлы карарына
Килештерү кәгазе

«Хөкем ителгәннәрнең җәзаларын үтәү өчен мәҗбүри эш төрләрен һәм объектларның төрләрен билгеләү турында»
(документның исеме һәм атамасы)

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Н.А. Баймяшкина

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы буенча
Россия ҖҮФХИ ФКУнең
Нурлат муниципальара филиалы начальнигы
эчке хезмәт майоры Р.Ф. Хәмидуллин